КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 сентябрь г.Казань № 832

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципаль-ара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 26 февраль, 119 нчы карары белән расланган Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 26 февраль, 119 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 8 август, 645 нче; 2018 ел, 31 октябрь, 973 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата планлы тикшерүләр үткәрү, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлегенә бирелгән куркыныч категориясенә карап, түбәндәге вакыт аралыгы белән гамәлгә ашырыла:

урта куркыныч категориясе өчен – дүрт елга бер тапкырдан ешрак һәм биш елга бер тапкырдан сирәк булмаган;

уртача куркыныч категориясе өчен – алты елга бер тапкырдан ешрак һәм сигез елга бер тапкырдан сирәк булмаган.

Эшчәнлекләре түбән куркыныч категориясенә кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә мөнәсәбәттә планлы тикшерүләр үткәрелми.»;

14 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Планлы тикшерүне планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертү өчен нигез булып тикшерү үткәрелә торган елда түбәндәге датадан билгеләнгән вакыт чоры узып китү тора:

а) куркынычның III һәм (яки) IV классларындагы куркыныч җитештерү объектларын юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдалана башлау;

б) III һәм (яки) IV классларындагы гидротехник корылмаларны юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдалана башлау;

в) муниципаль берәмлекләр мәнфәгатьләрендә 330 киловольтка кадәр көчәнешле электр челтәре хуҗалыгы объектларын юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдалана башлау;

г) муниципаль берәмлекләр мәнфәгатьләрендә түбәндәге үзәкләштерелгән системаларны юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдалана башлау;

салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) су чыгару, мондый системаларның аерым объектларын;

кайнар су белән тәэмин итү, мондый системаларның аерым объектларын;

д) юридик затларны (аларның структур бүлекчәләрен) һәм шәхси эшмәкәрләрне яки алар карамагындагы оешмаларны һәм бу оешмаларның структур бүлекчәләрен гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системалары көчләре составына билгеләнгән тәртиптә кертү (керү);

е) бер үк вакытта 1 000нән 5 000гә кадәр кеше булырга мөмкин булган объектларны юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан файдалана башлау;

ж) юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан түбәндәге эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау:

балалар ялын һәм аларны савыктыруны оештыру өлкәсендә;

яшәү белән тәэмин итеп, социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә;

стационар медицина ярдәме күрсәтү өлкәсендә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тиз үсә торган куркыныч табигать күренешләренең килеп чыгу куркынычына дучар булган территорияләрдә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан һәм химик куркыныч объектлар тирәсендә ачыкланган мөмкин булган химик зарарлану

зоналары чикләре белән билгеләнгән тиз үсә торган куркыныч техноген процесслар барлыкка килү куркынычына дучар булган территорияләрдә;

з) әлеге пунктның «а» – «ж» пунктчаларында күрсәтелгән оешмаларга, юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә соңгы планлы тикшерү үткәрү тәмалану.

18 нче пунктның «а» һәм «г» пунктчаларында «югары һәм сизелерлек» сүзләрен «урта һәм уртача» сүзләренә алыштырырга;

19 нчы пунктның беренче абзацында, «а» һәм «в» пунктчаларында «югары һәм сизелерлек» сүзләрен «урта һәм уртача» сүзләренә алыштырырга;

21 нче пунктта татар текстында «билгеләнгән тәртиптә юридик затка яки шәхси эшмәкәргә алар эшчәнлеген куркыныч категориясенә кертү турында мәгълүматны», «кертә» сүзләрен шул ук эзлеклелектә «мондый сорау кергән көннән 15 эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә аларга аларның эшчәнлегенә бирелгән риск категориясе турындагы мәгълүматны», «җибәрә» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 15 сентябрь, 832 нче
карары редакциясендә)

Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне
билгеле бер куркыныч категориясенә кертү
критерийлары

1. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлеген бәяләүне һәм юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлегенең потенциаль тискәре нәтиҗәләре авырлыгын исәпкә алып, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге түбәндәге куркыныч категорияләренә кертелергә тиеш:

а) урта куркыныч категориясенә – түбәндәгеләрне файдалануны гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге:

куркынычның III һәм (яки) IV классларындагы куркыныч җитештерү объектларын;

III һәм (яки) IV классларындагы гидротехник корылмаларны;

муниципаль берәмлекләр мәнфәгатьләрендә 330 киловольтка кадәр көчәнешле электр челтәре хуҗалыгы объектларын;

муниципаль берәмлекләр мәнфәгатьләрендә түбәндәге үзәкләштерелгән системаларны:

салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) су чыгару, мондый системаларның аерым объектларын;

кайнар су белән тәэмин итү, мондый системаларның аерым объектларын;

б) уртача куркыныч категориясенә – юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең эшчәнлеге, әгәр дә бу юридик затлар (аларның структур бүлекчәләре) һәм шәхси эшмәкәрләр яки алар карамагындагы оешмалар һәм бу оешмаларның структур бүлекчәләре:

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системалары көчләре составына билгеләнгән тәртиптә кертелгән (кергән);

бер үк вакытта 1 000нән 5 000гә кадәр кеше булырга мөмкин булган объектларны файдалануны гамәлгә ашыра;

түбәндәге эшчәнлекне гамәлгә ашыра:

балалар ялын һәм аларны савыктыруны оештыру өлкәсендә;

яшәү белән тәэмин итеп, социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә;

стационар медицина ярдәме күрсәтү өлкәсендә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары белән билгеләнгән тиз үсә торган куркыныч табигать күренешләренең килеп чыгу куркынычына дучар булган территорияләрдә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары һәм химик куркыныч объектлар тирәсендә ачыкланган мөмкин булган химик зарарлану зоналары чикләре белән билгеләнгән тиз үсә торган куркыныч техноген процесслар барлыкка килү куркынычына дучар булган территорияләрдә;

в) түбән куркыныч категориясенә – башка юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеге.

2. Урта һәм уртача куркыныч категориясенә кертелергә тиешле юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге законлы көченә кергән һәм соңгы планлы тикшерүдә ачыкланган Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 20.5 һәм 20.6 статьяларында каралган административ хокук бозулар кылган өчен юридик затка һәм (яки) аның вазыйфаи затларына, шәхси эшмәкәргә административ җәза билгеләү турында суд карары булмаганда шул ук эзлеклелектә уртача һәм түбән куркыныч категориясенә кертелергә тиеш.

3. Уртача һәм түбән куркыныч категориясенә кертелергә тиешле юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге законлы көченә кергән һәм соңгы планлы тикшерүдә ачыкланган Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 9.19 статьясы, 19.4 статьясының 1 өлеше, 19.5 статьясының 1 өлеше, 19.5.1, 19.6, 19.7, 20.5 һәм 20.6 статьяларында каралган административ хокук бозулар кылган өчен юридик затка һәм (яки) аның вазыйфаи затларына, шәхси эшмәкәргә административ җәза билгеләү турында суд карары булганда шул ук эзлеклелектә урта һәм уртача куркыныч категориясенә кертелергә тиеш.